ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 36-2-45, факс: (84379) 36-2-45.

21 ноября 2025 г. №1

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
карар

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

(- Каинки авылындагы юлларны ремонтлау өчен асфальт гранулат сатып алу, товарны билгеләнгән урынга илтүче хисабына җирлек ихтыяҗлары өчен китерү) дигән сорау буенча 2025 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 32 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 17 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенында 16 катнашучы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен – җыенда 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылы территориясендә гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, 2026 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? -

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

(-Каинки авылындагы юлларны ремонтлау өчен асфальт гранулат сатып алу, товарны билгеләнгән урынга илтүче хисабына җирлек ихтыяҗлары өчен китерү) дигән сорау буенча карарны таныырга.

3. Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче С. В. Бурукин